СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.09.2019 № 84/1
На № _________ от_____________

# КАРАР

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге чиген «Яр Чаллы шәһәре»
муниципаль берәмлеге белән чиктәшлек буенча үзгәртү
инициативасын карау һәм Тукай муниципаль районы
Советының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге
Шәһәр Советы инициативасын хуплау хакында»
карар проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 13 маддәсе, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә һәм халык фикерен ачыклау максатында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәшлек буенча (алар составына керүче торак пунктларны башка муниципаль берәмлекләр территорияләренә кертүгә китерми торган) үзгәртү турында инициативаны карарга.

2. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәшлек буенча (алар составына керүче торак пунктларны башка муниципаль берәмлекләр территорияләренә кертүгә китерми торган) үзгәртү мәсьәләсе буенча халык тыңлауларын үткәрүне 2019 елның 14 октябренә 18.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, Тукай муниципаль районы Советының утырышлар залы.

3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар эш көннәрендә, әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән алып 2019 елның 14 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 203 кабинет, тел. 8 (8552) 70-16-06 (Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге).

4. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Л.Г. Авзаловка йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев